ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
17.02.2020

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№261

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Новопольский авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү турында

Социаль, икътисадый, экологик һәм башка факторларның барсыннан чыгып территорияләрне билгеләү максатларында, авыл җирлеге территориясен тотрыклы үстерүне тәэмин итү, әлеге территорияне тормышның уңай шартлары булган комплекслы тотрыклы үстерүне, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итүне саклый торган инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» гы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Новопольский авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләүгә керешергә.
2. Новопольский авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү буенча комиссия төзергә, аның составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Новопольский авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү комиссиясе турындагы Нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Комиссиягә 2020 елның 01 июненә кадәр Новопольский авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү эшләрен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган тәртиптә башкарырга.
5. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек , ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Новопольский авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү турындагы хәбәрләрне Зеленодольск муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин

ЗМР Башкарма комитетының
2020 елның 17 февралендәге
261 номерлы карарына
1нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ НОВОПОЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ ПРОЕКТЫН ӘЗЕРЛӘҮ КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ

**Комиссия рәисе:**

| | |
|---|---|
| Старостин А.В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары; |

**Комиссия рәисе урынбасары:**

| | |
|---|---|
| Сергеев П.Н. | «ЗМР Архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ җитәкчесе; |

**Комиссия секретаре:**

| | |
|---|---|
| Левочкина Н.Н. | «ЗМР Архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ генераль планы бүлеге баш белгече; |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Якупов Н.Ю. | Новопольский авыл җирлеге башлыгы; |
| Алексахина А.Ю. | «ЗМР мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ җитәкчесе; |
| Нургалеева Э.А. | Зеленодольск муниципаль районы; Советының юридик бүлеге начальнигы; |
| Антонова М.М. | «Зеленый Дол» «Инвестицион үзәк» АУ җитәкчесе; |

ЗМР Башкарма комитетының
2020 елның 17 февралендәге
261 номерлы карарына
2 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОВОПОЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ ПРОЕКТЫН ӘЗЕРЛӘҮ КОМИССИЯСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1.ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Новопольский авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - комиссия) территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру нигезендә территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү өчен төзелә.

1.2. Комиссия даими эшләүче булып тора һәм үз эшчәнлеген РФ Шәһәр төзелеше кодексы, башка норматив актлар нигезендә тормышка ашыра.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, «Новопольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Комиссия дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр, шулай ук кызыксынучы юридик һәм физик затлар белән үзара хезмәттәшлектә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

## 2.КОМИССИЯ СОСТАВЫ

2.1. Комиссия составы ЗМР Башкарма комитеты карары белән раслана.
2.2.Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

## 3. КОМИССИЯ КОМПЕТЕНЦИЯСЕ

3.1. Комиссия компетенциясенә түбәндәгеләр керә:
3.1.1. Территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру нигезендә территорияләрне эзлекле рәвештә булдыру һәм камилләштерү процессын оештыру, шул исәптән Зеленодольск муниципаль районының «Новопольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү;
3.1.2. Зеленодольск муниципаль районының «Новопольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау;

3.1.3. «Зеленодольск муниципаль районының Новопольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү буенча гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру;
3.1.4. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча йомгак ясау, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә тәкъдимнәр әзерләү.

## 4. КОМИССИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТӘРТИБЕ

4.1. Комиссия утырышлары кирәк булган саен җыела, әмма кварталга бер тапкырдан да ким түгел.
4.2. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.
4.3. Комиссия карары комиссиянең катнашучылардан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.
4.4. Гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәре Комиссия рәисе исеменә җибәрелә. Комиссия рәисе аларны Комиссия утырышларында ике атна дәвамында карауны тәэмин итә.
4.5. 4.4 пунктта күрсәтелгән тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителә, ул беркетмәдә чагылдырыла.